КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 7 июнь г.Казань № 480

Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципальара маршрутлары буенча халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өчен туристик автобуслар сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында транспорт оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципальара маршрутлары буенча халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өчен туристик автобуслар сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында транспорт оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 7 июнь, 480 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципальара маршрутлары буенча халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өчен туристик автобуслар сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында транспорт оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципальара маршрутлары буенча халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өчен туристик автобуслар сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында транспорт оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр транспорт оешмаларына Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципальара маршрутлары буенча халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өчен туристик автобуслар сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында бирелә.

3. Субсидияләр Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына (алга таба – Министрлык) бирелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга бирелә.

4. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчаларын төп бүлүче булып Министрлык тора.

5. Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципальара маршрутлары буенча халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өчен кимендә 50 урын сыйдырышлы туристлык автобусларын сатып алу белән бәйле чыгымнар финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып торган чыгымнар (субсидияләр бирелә торган чыгымнар) тора.

6. Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр алучылар – Татарстан Республикасы территориясендә җайга салынулы пассажирлар йөртү маршрутлары буенча теркәлгән һәм транспортта йөртүне гамәлгә ашыручы транспорт оешмалары (алга таба – субсидия алучы).

7. Субсидия алучыларны сайлап алу критерийлары булып тора:

1) субсидия алучыда Татарстан Республикасында даими пассажирлар йөртү маршрутлары буенча пассажирлар йөртү хокукын раслый торган документ булу (Татарстан Республикасы территориясе буенча узучы даими муниципальара маршрутлар

буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хокукына шартнамә яисә даими пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык);

2) субсидия алучы тарафыннан эшләп чыгарылган еллары субсидия ал елына туры килә торган автобусларны сатып алу.

8. Субсидияләр субсидия бирү турында килешү төзү планлаштырыла торган айдан алдагы айның беренче көненә түбәндәге таләпләргә туры килә торган субсидия алучыларга бирелә:

субсидия алучының салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаска тиеш;

субсидия алучының Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында бүтән түләнмәгән бурыч булмаска тиеш;

субсидия алучы – юридик зат үзгәртеп кору, бетерү, банкротлык процессында булырга тиеш түгел, ә субсидия алучы – шәхси эшмәкәр эшчәнлеген шәхси эшмәкәр сыйфатында туктатырга тиеш түгел;

чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясенең Финанс министрлыгы белән раслана торган Салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм финанс операцияләрен үткәргәндә мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмый торган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория аның теркәлү урыны булган чит ил юридик затларның катнашу өлеше барысы бергә 50 процenttан артыграк булган Россия юридик заты түгел;

субсидия алучы әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы түгел.

9. Субсидия алу өчен субсидия алучы Министрлыкка субсидия бирү турында гаризаны (алга таба – гариза) ирекле формада кәгазьдә, түбәндәге документларны кушып җибәрә:

субсидия алучыда салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар түләү буенча үтәлмәгән бурычның булмавын раслаучы документлар;

субсидия алучының Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында бүтән түләнмәгән бурыч булмавын раслаучы документлар;

субсидия алучы – юридик зат үзгәртеп кору, бетерү, банкротлык процессында булмаген, ә субсидия алучы – шәхси эшмәкәр эшчәнлеген шәхси эшмәкәр сыйфатында туктатылмаган шартларда;

чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясенең Финанс министрлыгы белән раслана торган Салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм финанс операцияләрен үткәргәндә мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмый торган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория аның теркәлү урыны

булган чит ил юридик затларның катнашу өлеше барысы бергә 50 проценттан артыграк булган Россия юридик заты булмауны раслый торган документлар;

субсидия алучы әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмый дип раслый торган документлар;

Татарстан Республикасында даими пассажирлар йөртү маршрутлары буенча пассажирлар йөртү хокукын раслый торган документ күчермәсе (Татарстан Республикасы территориясе буенча узучы даими муниципальара маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хокукына шартнамә яисә даими пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык);

50 урын сыйдырышлы туристлык автобусларын сатып алу белән бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс ягыннан тәэмин итү өчен – автобуслар сатып алу планлаштырыла торган мәгълүмат;

50 урын сыйдырышлы туристлык автобусларын сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен – әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга киткән чыгымнарның күләмен раслаучы документлар күчермәләре.

Тапшырылган документларның күчермәләре субсидия алучы тарафыннан раслана.

10. Субсидия алучы үз инициативасы белән салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсен тапшырырга хокуклы.

Субсидия алучы әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән документ тапшырмаган очракта, Министрлык күрсәтелгән документны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

11. Министрлык әлеге Тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән гаризаны аның кергән көнендә терки.

12. Министрлык гаризаны теркәү датасыннан башлап эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә аны карап тикшерә һәм субсидияләр бирү яки субсидияләр бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

13. Кабул ителгән карар нәтиҗәләре турында хәбәрнамә Министрлык тарафыннан субсидия алучыга тиешле карар кабул ителгән көннән соң бер көн эчендә язма рәвештә җибәрелә.

14. Субсидияләр бирүдән баш тарту өчен нигез булып тора:

субсидия алучы тарафыннан бирелгән документларның әлеге Тәртипнең 9 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки күрсәтелгән документларның тулы күләмдә тапшырылмавы (тулы булмаган күләмдә тапшыру) ;

субсидия алучы тапшырган мәгълүматның дөрес булмавы;

субсидия алучының әлеге Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән критерийларга туры килмәве;

бюджет йөкләмәләре лимитлары булмау.

Субсидия алучы субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү алган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә кире кагу өчен нигез булган тиешле төзәтмәләрне бетерү шарты белән, эшләп бетерелгән документларны яңадан тапшырырга хокуклы.

Әлеге пунктның бишенче абзацында күрсәтелгән документларны карап тикшерү Министрлык тарафыннан әлеге Тәртипнең 11 – 13 пунктлары нигезендә башкарыла.

15. Субсидия Министрлык һәм субсидия алучы арасында субсидия бирү турындагы килешү нигезендә бирелә, аңа карата субсидия бирү турында карар кабул ителә (алга таба – килешү).

Килешү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән үрнәк форма нигезендә субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә исәпләнә.

16. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, аны Татарстан Республикасы бюджетыннан бирү шартлары һәм тәртибе;

субсидия күчерү вакыты;

субсидия алучы тарафыннан максатчан файдалануны контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

әлеге Тәртип белән билгеләнгән шартлар бозылган очракта килешүне өзү тәртибе;

субсидияләрдән файдалану турында хисап бирү формасы, вакыты һәм тәртибе;

Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрне кире кайтару тәртибе һәм вакыты;

Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүне гамәлгә ашыру хокукы;

субсидия куллану нәтиҗәлелегенең максатчан күрсәткече, субсидия алучыга аның ирешүе буенча йөкләмәләр һәм субсидияләр нәтиҗәлелегенең күрсәткече җитмәгән очракта нәтиҗәләр;

алынган субсидияләр хисабына чит ил валютасында сатып алу тыю, югары технологияле чит ил җиһазларын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (җибәргәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш.

17. Министрлык субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә кредит оешмаларында ачылган субсидия алучыларның исәп-хисап счетларына субсидияләр күчерә.

18. Кимендә 50 урын сыйдырышлы туристлык автобусларын сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен субсидияләр күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$С = К_{пр.авт.} \times 2{,}5 \ \text{млн. рублей},$$

монда:

С – кимендә 50 урын сыйдырышлы туристлык автобусларын сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс ягыннан тәэмин итү (каплау) максатларында бирелә торган субсидия күләме;

$К_{пр.авт.}$ – кимендә 50 урын сыйдырышлы сатып алына торган (сатып алынган) туристик автобуслар саны;

2,5 млн.рублей – кимендә 50 урын сыйдырышлы туристлык класслы 1 автобуска бирелә торган субсидия күләме.

19. Кимендә 50 урын сыйдырышлы туристик автобуслар сатып алуга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин иткәндә субсидия алучы тарафыннан субсидия кулланунын нәтиҗәлелеге күрсәткече ($E_{iфо}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$E_{iфо}=\frac{K_{фактij}}{K_{плij}}\times 100\%,$$

монда:

$K_{плij}$ – гаризада күрсәтелгән берәмлек туристик автобуслар сатып алырга планлаштырыла;

$K_{фактij}$ – 2020 елның 1 гыйнварына фактта сатып алынган туристлык автобуслары саны.

Кимендә 50 урын сыйдырышлы туристлык автобусларын сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен кайтарганда субсидия алучы тарафыннан субсидия куллануның нәтиҗәлелеге күрсәткече ($E_{iфв.}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$E_{iфв.}=\frac{K_{АММ}}{K_{ПА}}\times 100\%,$$

монда:

$K_{АММ}$ – сатып алынган берәмлек туристлык автобусларыннан ГЛОНАСС (ГЛОНАСС/GPS) спутник навигациясе системасы мәгълүматлары буенча фактта даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципальара маршрутларына транспорт хезмәте күрсәтүгә файдаланганнар саны;

$K_{ПА}$ – 2020 елның 1 гыйнварына фактта сатып алынган туристлык автобуслары берәмлекләре саны.

20. Субсидияләр бирү елыннан соң киләсе елның 1 гыйнварына кадәр субсидия алучылар Министрлыкка килешүдә каралган форма һәм тәртип нигезендә субсидияләрдән файдалану һәм субсидияләрдән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең әһәмиятенә ирешү турында хисап бирәләр.

21. Субсидия алучы хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм субсидияне максатсыз файдалану өчен закон нигезендә җавап тота.

22. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары әлеге Тәртип һәм килешү белән билгеләнгән субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүне гамәлгә ашыралар.

23. Субсидияләр Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган субсидия алучы тарафыннан субсидияләр биргәндә билгеләнгән шартларны бозу;

субсидия алучы тарафыннан субсидияләр алу өчен дөрес булмаган (тулы булмаган) мәгълүматлар һәм документлар тапшыру;

килешүдә билгеләнгән вакытта субсидияләрдән файдалану турында хисап тапшырмау;

субсидияләр чараларын максатсыз файдалану;

субсидияләр бирү нәтиҗәлелегенең күрсәткече мәсгънәсенә ирешмәү.

24. Килешүдә каралган очракларда хисап финанс елында файдаланылмый торган кимендә 50 урын сыйдырышлы туристик автобуслар сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итүгә субсидия калдыклары хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты keremенә кире кайтарылырга тиеш.

25. Субсидия алучы әлеге Тәртипнең 23 һәм 24 пунктларында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару вакытын бозган очракта, Министрлык субсидияне кире кайтару вакыты чыккан көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән җиде көн эчендә күрсәтелгән акчаларны Татарстан Республикасы бюджетына законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

26. Субсидияләрнең максатчан һәм нәтиҗәле кулланылышын тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан законнар нигезендә башкарыла.

---